КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 12 май г.Казань № 379

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Федераль бюджеттан бүлеп бирелә торган субвенцияләр исәбеннән гражданнарның аерым категорияләренә торак сатып алу өчен субсидияләр бирү ту-рындагы нигезләмәне раслау хакында» 2006 ел, 7 июнь, 275 нче карары белән расланган Федераль бюджеттан бүлеп бирелә торган субвенцияләр исәбеннән гражданнарның аерым категорияләренә торак сатып алу өчен субсидияләр бирү турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Федераль бюджеттан бүлеп бирелә торган субвенцияләр исәбеннән гражданнарның аерым категорияләренә торак сатып алу өчен субсидияләр бирү турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2006 ел, 7 июнь, 275 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 ел, 16 февраль, 47 нче; 2007 ел 14 июнь, 235 нче, 2008 ел, 26 ноябрь, 832 нче; 2009 ел, 27 февраль, 115 нче; 2009 ел, 8 апрель, 209 нчы; 2009 ел, 21 август, 571 нче; 2010 ел, 2 февраль, 229 нчы; 2015 ел, 4 февраль, 61 нче; 2015 ел, 12 март, 146 нчы; 2016 ел, 13 май, 305 нче; 2016 ел, 26 май, 359 нчы; 2016 ел, 19 октябрь, 762 нче; 2018 ел, 15 февраль, 90 нчы; 2018 ел, 24 март, 166 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Гражданнарның аерым категорияләренә федераль бюджеттан бүлеп бирелә торган субвенцияләр исәбеннән торак сатып алу өчен субсидияләр бирү турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Бу Нигезләмәнең 1 нче пунктында күрсәтелгән гражданнарга торак сатып алу өчен субсидияләр бирү гражданнар бу Нигезләмәнең 1 нче пунктында күрсәтелгән вакытларда торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлар сыйфатында исәпкә баскан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре башкарма комитетлары исемлекләре (җитәкче һәм мөһер белән таныкланган) нигезендә Министрлык тарафыннан төзелгән бу Тәртипнең 2 нче пунктындагы «а» пунктчасында күрсәтелгән гражданнар категорияләре арасыннан субсидия алучыларның җыелма исемлеге, бу Тәртипнең 2 нче пунктындагы «б» пунктчасының икенче – дүртенче абзацларында күрсәтелгән гражданнар категорияләре арасыннан субсидия алучыларның җыелма исемлеге һәм бу Тәртипнең 2 нче пунктындагы «б» пунктчасының бишенче, алтынчы абзацларында күрсәтелгән гражданнар категорияләре арасыннан субсидия алучыларның җыелма исемлеге (алга таба – җыелма исемлекләр) нигезендә чират тәртибендә башкарыла.».

Җыелма исемлекләр субсидия алучы гражданнар торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлар буларак исәпкә куелган шул ук хронологик эзлеклелектә төзелә. Бер үк көнне исәпкә куелган гражданнар җыелма исемлектә алфавит тәртибендә күрсәтелә.

Субсидияләрне чираттан тыш алу хокукына Бөек Ватан сугышы инвалидлары, Бөек Ватан сугышында катнашучылар, I төркем хәрби хәрәкәтләр инвалидлары, шулай ук эчке эшләр органнары, Дәүләт янгынга каршы хезмәте, җинаять-үтәтү системасы учреждениеләре һәм органнарының хәрби хезмәт йөкләмәләрен (хезмәт йөкләмәләрен) үтәгәндә алынган яралану, контузия яки гариплек аркасында I төркем инвалиды булган хәрби хезмәткәрләре һәм рядовой һәм җитәкчелек составларындагы затлары; субсидияләрне беренче чиратта алу хокукына II, III төркемнәр хәрби хәрәкәтләр инвалидлары, шулай ук эчке эшләр органнары, Дәүләт янгынга каршы хезмәте, җинаять-үтәтү системасы учреждениеләре һәм органнарының хәрби хезмәт йөкләмәләрен (хезмәт йөкләмәләрен) үтәгәндә алынган яралану, контузия яки гариплек аркасында II, III төркемнәр инвалидлары булган хәрби хезмәткәрләре һәм рядовой һәм җитәкчелек составларындагы затлары, «Блокадалы Ленинградта яшәүчегә» билгесе белән бүләкләнгән затлар, хәрби хәрәкәтләр ветераннары, һәлак (вафат) булган Бөек Ватан сугышы инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышында катнашучылар гаиләләре әгъзалары, Бөек Ватан сугышында җирле һава һөҗүменә каршы оборонаның объект һәм авария командаларындагы үзүзен саклау төркемнәренең шәхси составы исәбеннән һәлак булган затлар гаиләләре әгъзалары, шулай ук Ленинград шәһәре госпитальләренең һәм хастаханәләренең һәлак булган хезмәткәрләре гаиләләре әгъзалары, һәлак (вафат) булган хәрби хәрәкәтләр инвалидлары һәм хәрби хәрәкәтләр ветераннары гаиләләре әгъзалары, эчке эшләр органнары, Дәүләт янгынга каршы хезмәте, җинаять-үтәтү системасы учреждениеләре һәм органнары һәм дәүләт куркынычсызлыгы органнарының хәрби хезмәт йөкләмәләрен (хезмәт йөкләмәләрен) үтәгәндә һәлак булган хәрби хезмәткәрләре, рядовой һәм җитәкчелек составларындагы затлары гаиләләре әгъзалары, хәрби хәрәкәтләр районнарында хәбәрсез югалган дип билгеләнгән тәртиптә танылган, тоткынлыкта һәлак булган хәрби хезмәткәрләр гаиләләре әгъзалары, инвалидлар һәм инвалид балалары булган гаиләләр ия.

1941 елның 22 июненнән 1945 елның 3 сентябренә кадәрге чорда гамәлдәге армия составына кермәгән хәрби частьләрдә, учреждениеләрдә, хәрби уку-укыту йортларында кимендә алты ай хәрби хезмәт иткән хәрби хезмәткәрләр, әлеге чорда хезмәт итү өчен СССР орденнары һәм медальләре белән бүләкләнгән хәрби хезмәткәрләр, шулай ук Бөек Ватан сугышы чорында һава һөҗүменә каршы оборона, җирле һава һөҗүменә каршы оборона объектларында, гамәлдәге фронтларның тыл чикләре кысаларында оборона корылмалары, хәрби-диңгез базалары, аэродромнар һәм башка хәрби объектлар, гамәлдәге флотларның операция зоналары төзелешендә, тимер һәм автомобиль юлларының фронт янындагы участокларда эшләгән затлар, Бөек Ватан сугышы башланганда башка дәүләтләр портларында мәҗбүри тотып торылган транспорт флоты суднолары экипажлары үзләре биләгән хезмәт торак урыннарыннан чыгарылган очракта субсидияләр белән тәэмин ителә.

II, III төркемнәр хәрби хәрәкәтләр инвалидлары, шулай ук эчке эшләр органнары, Дәүләт янгынга каршы хезмәте, җинаять-үтәтү системасы учреждениеләре һәм органнарының хәрби хезмәт йөкләмәләрен (хезмәт йөкләмәләрен) үтәгәндә алынган яралану, контузия яки гариплек аркасында II, III төркемнәр инвалидлары булган хәрби хезмәткәрләре һәм рядовой һәм җитәкчелек составларындагы затлары арасыннан субсидияләр алучыларга I төркем инвалидлыгы бирелгән очракта, алар субсидияләрне чираттан тыш алу хокукын ала.

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең башкарма комитетлары торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлык өлешендә исемлекләрне актуальләштерүне гамәлгә ашырырга һәм мондый хәлләр ачыкланган вакыттан 10 эш көне эчендә гражданнарда субсидияләр алу хокукын үзгәртүгә китерә торган хәлләр барлыкка килү турында Министрлыкка хәбәр итәргә тиеш.

Министрлык җыелма исемлекләр нигезендә Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы тарафыннан раслана торган форма буенча торак белән тәэмин итү буенча социаль ярдәм күрсәтү чараларыннан файдалану хокукына ия гражданнар исемлекләрен (алга таба – Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы тарафыннан расланган форма буенча төзелгән гражданнар исемлекләре) төзи һәм аларны, «Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән таләпләрне үтәп, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтына (алга таба – рәсми сайт) урнаштыра.

Җыелма исемлекләргә үзгәрешләр кертелгән очракта, Министрлык Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы тарафыннан расланган форма буенча төзелгән гражданнар исемлекләрен актуальләштерүне һәм аларны, һәр кварталның беренче аеның 5еннән дә соңга калмыйча, рәсми сайтка урнаштыруны гамәлгә ашыра.

Шул ук вакытта рәсми сайтта агымдагы календарь елда элек урнаштырылган гражданнар исемлекләренә барлык сылтамалар сакланып калырга тиеш.»;

8 нче пунктның бишенче абзацында «аңа федераль бюджеттан акча бүлеп бирү турында» сүзләрен «аңа торак сатып алуга субсидия бирү турында» сүзләренә алыштырырга;

9 нчы пунктта «акча бүлеп бирү турында» сүзләрен «субсидия бирү турында» сүзләренә алыштырырга;

13 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«13. Министрлык территориаль социаль яклау органыннан гражданнар тарафыннан тапшырылган шартнамәләр турында мәгълүмат алынган көннән 35 эш көне эчендә акчаны, электрон (TXT форматында) мәгълүмат йөртү җайланмасы белән вәкаләтле банкның һәр бүлеге буенча субсидия алучылар реестрларын теркәп, Министрлыкның вакытлыча эш итүгә керә торган акча белән операцияләрне исәпкә алу өчен билгеләнгән шәхси счетыннан вәкаләтле банкның исәп-хисап счетына күчерүне тәэмин итә. Реестрда түләү йөкләмәсенең номеры һәм датасы күрсәтелергә һәм субсидия алучының фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда), аның паспорт мәгълүматлары, теркәлү адресы, алучыга бирелергә тиешле субсидия суммасы, агымдагы (банк) счетының номеры булырга тиеш.»;

15 нче пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Бу очракта субсидия алучы үзенең торак сатып алуга субсидия алу хокукын югалтмый, җыелма исемлектән төшереп калдырылмый һәм алга таба гариза бирү нигезендә бу Нигезләмәнең 7 нче пункты белән каралган тәртиптә төзелә торган исемлеккә кертелергә тиеш.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин